**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 31 март № 201

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 июль, 546 нчы, 2016 ел, 8 февраль, 76 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнар нормативларын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрдә:

2.7 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тәрбиячеләрнең база оклады (эш хакы ставкасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карары нигезендә мәгариф хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүнең дүрт разрядлы тариф челтәренең IV разрядына туры килә;

2.9 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$« FOT^{t}_{vosvz} = \frac{(y \times x \times (1/n_{vz.восп} \times b_{восп}) \times e \times k_{v.восп} \times 12 + y \times x / n_{vz.восп} \times O_b \times r^t)}{m_{vzq\lim}} \times (1 + K_{замещ}),»;$$

түбәндәге эчтәлекле ундүртенче абзац өстәргә:

«$K_{замещ}$ – 2 процентка тигез кабул ителгән алыштыру коэффициенты.»;

2.10 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«педагог-психологларның база оклады (эш хакы ставкасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карары нигезендә мәгариф хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүнең дүрт разрядлы тариф челтәренең IV разрядына туры килә.»;

2.13 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка педагогика персоналының база оклады (эш хакы ставкасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карары нигезендә шәһәр һәм авыл җирлегендә мәгариф хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүнең дүрт разрядлы тариф челтәренең IV разрядына туры килә.»;

2.15 пунктта:

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында укулар төрләре буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларның атналык дәресләр йөкләнеше сәгатьләре саны

(1 тәрбияләнүчегә сәгатьләр)

| Дәресләр төрләре | Балаларның атналык белем алу йөкләнеше астрономик сәгатьләре саны | |
|---|---|---|
| | 1,5 яшьтән 3 яшькәчә | 3 яшьтән зурырак |
| Физкультура-сәламәтләндерү циклы дәресләре | 0,050 | 0,125 |
| Эстетика циклы дәресләре | 0,050 | 0,142 |
| Балаларның югары танып белү активлыгын һәм акыл эшчәнлеген таләп итә торган дәресләр | 0,050 | 0,190»; |

«$Z_3$ – балаларның югары танып белү активлыгын һәм акыл эшчәнлеген таләп итә торган дәресләрне укытучыларның эш хакы ставкасына сәгатьләр саны (атнага 18 сәгать);» абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Z_3$ – балаларның югары танып белү активлыгын һәм акыл эшчәнлеген таләп итә торган дәресләрне укытучыларның эш хакы ставкасына сәгатьләр саны (атнага 36 сәгать);»;

2.16 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка педагогика персоналының база оклады (эш хакы ставкасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карары нигезендә шәһәр һәм авыл җирлегендә мәгариф хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүнең дүрт разрядлы тариф челтәренең IV разрядына туры килә.»;

3.1 пунктта:

5 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне уку һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итү нормалары

(данә)

| Предмет исеме | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|
| Уеннар, уенчыклар | 12,00 |
| Уеннар өчен инвентарь һәм башка уку һәм тәрбия чаралары | 5,26»; |

3.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«R_{vy}obes = \sum_{i_1=1}^{n=1} N_{ilvtoy} \times C_{iltoy},»;$$

бишенче, алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$N_{i1vtoy}$ – әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 3.1 пункты нигезендә кулланыла торган тәрбияләнүчеләрне уку һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итү нормалары;

$C_{i1toy}$ – әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 3.1 пункты нигезендә кулланыла торган уку һәм тәрбия чаралары бәясе;»;

тугызынчы, унынчы абзацлар үз көчләрен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мөлкәтне карап тотуга норматив чыгымнарны, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарны, элемтә хезмәтләренә норматив чыгымнарны, бассейннарны карап тотуга норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрдә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«дезинфекция хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар;

җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар.»;

1.2 пунктта «1 кв. метрга 1,5 сум» сүзләренә кадәр «бер айга» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 1.4, 1.5 пунктлар өстәргә:

«1.4. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында дезинфекция хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар бүлмәнең (бинаның) ягып җылытыла торган мәйданының 1 кв.метрына 0,24 сумнан исәпләп билгеләнә.

1.5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар бүлмәнең (бинаның) ягып җылытыла торган мәйданының 1 кв.метрына 1,15 сумнан исәпләп билгеләнә.».

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\201.docx